**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**02.03.2023 ел** **№82**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрь 16 номерлы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрь 16 номерлы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы карарына (Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 апрель 24 номерлы, 2022 елның 1 март 48 номерлы, 2022 елның 28 ноябрь 68 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Аукционда катнашу өчен дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча (задаток) кертә:

100 миллион сум һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;

100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 процентын.»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5.6.1 пунктын өстәргә:

«5.6.1. Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка алдан акча (задаток) кертүне раслый торган документ булып шушы счеттан өземтә тора.»;

1.3. 6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Аукционда катнашу өчен дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча (задаток) кертә:

100 миллион сум һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;

100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 процентын.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны  үземә йөклим.

Совет рәисе И.Э.Эмерханов